ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

19.12.2024

г.Казань

**КАРАР**

№ 658-104/тэ-2024

2025 елга кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга Казан шәһәренең «Органик синтез» гавами акционерлык җәмгыяте тарафыннан җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) тарифлар билгеләү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының «2040 елга кадәр Казан шәһәре муниципаль берәмлеген җылылык белән тәэмин итү схемасын раслау турында» 30.12.2021 ел, № 1543 боерыгы, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 19.12.2024 ел, №36-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Казан шәһәренең «Органик синтез» гавами акционерлык җәмгыятеннән (алга таба – «Казаньоргсинтез» ГАҖ) кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга бирелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) әлеге карар кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы

Л.В. Хәбибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
19.12.2024 № 658-104/тэ-2024
карарына кушымта

«Казаньоргсинтез» ГАҖ тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2025 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынулы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | су | Басым астында сайланма пар | | | | Әче һәм редукцияләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| | Казан шәһәре | | | | | | | |
| 1 | "Казаньоргсинтез" ГАҖ | | | | | | | |
| 1.1 | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 1 257,84 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 1 753,81 | - | - | - | - | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге